ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2019 ел 7 нче август** **Чистай шәһәре** **№ 407**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 елның 5 апрелендәге 168 номерлы
“Татарстан Республикасы Чистай Муниципаль
районы Башкарма комитетының
сәүдә бүлеге тарафыннан Чистай муниципаль
районы территориясендә алкоголь
продукциясенең ваклап сату буенча
муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда
хокуклар саклануы турындагы»
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Карар бирә:

1.Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 5 апрелендәге 168 номерлы “Татарстан Республикасы Чистай Муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә бүлеге тарафыннан Чистай муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясенең ваклап сату буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда хокуклар саклануы турындагы» административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.7 һәм 3.10 пунктларын түбәндәге эчтәлекле 2.1 һәм 2.2 пунктчалар өстәргә:

«2.1) башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, яисә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына буйсынган, алар карамагында бу документлар һәм (яки) мәгълүмат булган оешмалардан дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары алган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

2.2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган документлар һәм мәгълүматны Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына үз инициативасы буенча тапшырырга;»;

1.2. 2.2 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау өчен юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тиешле эшчәнлек өлкәсендә вәкаләтле вәкилгә тапшырылган дәүләт контроле органы тарафыннан әлеге хәбәрнамәне бирүне таләп итә торган эшләр башкарганда, яисә хезмәтләр күрсәткән очракта, эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы белдерүнамәгә ярашлы рәвештә,

эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә».

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Кашапова Л. Х. йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов